**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава Балыклы-Чукаевского сельского поселения**
**Рыбно-Слободского муниципального района**
индекс 422655 , с.Балыклы-Чукаево ,
ул.Центральная,д.8

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Балык Бистәсе муниципаль районы**
**Балыклы-Чукэй авыл җирлеге башлыгы**
индекс 422655, Балыклы-Чукэй авылы,
Узэк ур., 8 нче йорт

Тел.: (84361) 26357, факс: (84361) 26357, эл.адрес: Blc.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 10 ноябре Балыклы-Чукэй авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Балыклы-Чукәй, Иске Арыш һәм Керәшен Казысы авыл торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Балыклы-Чукәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Балыклы-Чукәй авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын беренче этабын 2021 елның 24 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Балыклы-Чукәй авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын икенче этабын 2021 елның 24 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Иске Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын беренче этабын 2021 елның 25 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.
4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Иске Арыш авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча

гражданнар җыенын икенче этабын2021 елның 25 ноябрендә 14 сәг. 00 минутка билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Керәшен Казысы авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенын 2021 елның 26 ноябрендә 10 сәг. 00 минутка билгеләргә.

6.Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләр исемлеген территориаль билге буенча бүләргә кирәк.

7.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Балыклы-Чукәй, Иске Арыш, Керәшен Казысы авыл торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Балыклы-Чукәй авыл җирлегенэ кергән авыл урамы юлларын кардан чистарту очен;

- су белән тәэмин итү системаларын рәсмиләштерү өчен;

-Балыклы-Чукәй авылынды Шәкуровлар урамын, Иске Арыш авылында М.Вахитов урамын олешчэ ремонтлау очен вак таш сатып алу очен;

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

8. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балыклы-Чукәй авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Балыклы-Чукәй авылы,Узәк урамы,8 йорт; Иске Арыш авылы, Узәк урамы, 23а йорт; Керәшен Казысы, Титов урамы, 11Б йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасынын хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

9. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Балыклы-Чукәй авыл җирлеге башлыгы И.С.Мазитов